

# Газизов Фаяз Мозаһит улы

*Республиканың баш офтальмологы*
*Хәзер шәхси практика үткәрә*

Халкыбызның милли-мәгариф-мәдәният усешендә Мулланур Вахитов исемендәге икенче номерлы Яр Чаллы урта мәктәбенең керткән өлеше искиткеч зур дип уйлыйм. Мәгарифнең усешен мәктәптән башка күз алдына китертеп тә булмый.

Мин Газизов Фаяз Мөҗәһит улы, 1947 нче елда Чаллы районы Калмаш авылында крестьян семьясында туып устем. Башлангыч мәктәбен Калмашта, аннан соң, күрше авылы Иске Гәрдәмдә 8-еллык мәктәпне яхшы билгеләргә тәмамладым.

Яшь вакыттан ук Туган илгә, Туган җиргә һәм Туган телгә зур ихтирам белән яшәдем. Аларның табигатен, телен һәм гореф-гадәтләрен яраттым, шулар белән үземне чын күңелдән бәхетле хис иттем. Барысыннан да бигрәк: ана теле, Бөек татар язучылары Габдулла Тукай, Каюм Насыйри, Муса Җәлил, Һади Такташ, Габдрахман Әпсәләмов һәм башкаларның әсәрләре күңелемә хуш килеп, гомерем буена миңа яшәргә, иҗат итәргә ярдәмче-маяк булып калдылар...

Минем беренче укытучыларым Асылгәрәева Бәрия, Сәлимгәрәева Әзһәрия апалар зур тырышлык һәм түземлек белән безгә тирән-төпле белем бирделәр. Зур рәхмәтләремне аларга җиткерәм. Аллаһ оҗмак түрендә булырга насыйп кылсын...

Үзебезнең телне, милләтне яраткан өчен, гәрчә бөек Рус телен мин “5” кә белсәм дә, 8 нче классны тәмамлагач икеләнеп тормыйча, Чаллы шәһәренең Вахитов исемендәге бердән бер татар урта мәктәбенә укырга килдем һәм ялгышмадым.

Бу – үзенчәлекле, бердәм укытучылар коллективы, үз эшләренә җаннары-тәннәре белән бирелгән күркәм шәхесләр, минем белемне яраттыруда һәм яраткан һөнәр сайлауда зур өлеш керттеләр....

Вахитов мәктәбендә ышанычлы дус егетләр таптым. Юмагулов Нәҗип һәм Әхмәтшин Рәшит белән өчәүләп, дәресләрдән кала-кала, төрле җәмгыять эшләрендә актив катнаштык. Үзешчән, сәнгать түгәрәгендә йөреп җыр-бию, шигырь сөйләү осталыгына өйрәндек. Мәктәп стенгазетасына рәсемнәр ясап, статьялар язып редактор, журналист вазифаларын башкардык. Шәһәр-ара, республика спорт

ярышларында  алдынгы урыннарны яуладык. Авыру, ятим кешеләргә кулдан килгәнчә ярдәм иттек. Мәктәп тормышында актив катнашуыбыз күпләргә үрнәк булып, әхлакый яктан дөрес тәрбия алуга этереш бирде, безнең, абруебызны күтәрде.

10 “А” классы җитәкчебез Солтанова Анна Ивановна үзенең тыныч холкы, сабырлыгы белән безне магнит кебек тартып-җыеп, тәрбия һәм белем биреп, чын Совет гражданы дәрәҗәсендә күтәрде. Ул  татар теле, әдәбият фәннәрен саф йөрәктән бирелеп һәм яратып безгә өйрәтте. Гомумән Анна Ивановна милли мәгариф, мәдәният үсешенә зур өлеш кертте. Без аңа аеруча Рәхмәтлебез!

Әйтеп киткәнемчә, укытучыларыбызның күбесе төпле белемле, интеллегент, сабыр холыклы, балаларны яратучы һәм безнең өчен тормышта үрнәк иделәр... Сабанаев Иван Александрович (мәктәпнең завучы) – математика, геометрия фәннәрен югары дәрәҗәдә өйрәтте. Бу фәннәрне татарча да, русча да югары уку йортларына кирәклек итеп үзләштердек. Фәрдиева Гөлсинә Фәрдиевна химиядән белем бирде,  бик таләпчән дә иде. Бу фәнне мин Медицина институты кергәндә “5”легә имтихан  тапшырып студент булдым.  Аңа хәзер дә зур рәхмәтләремне күңелемдә саклыйм.

Үзешчән сәнгать  коллективын җитәкләүче, бигрәк тә татар музыкасына, җырга, биюгә безне гашыйк иткән хөрмәтле Зөфәр Яруллович хәзер дә  чибәр, калын бөдрә чәчле, шомырт кара күзле, һәрвакыт елмаеп, ачык йөзе белән, аккордеонда уйнап күз алдына килә...

Үз туган телендә сөйләшеп, җырлап, биеп, шигырьләр язып, укып-укыган һәм эшләгән хезмәт коллективларында  дәрәҗәм күтәрелде, тормыш киртәләрең җиңәргә ярдәм иттеләр.  Алга барырга, чын мәхәббәтне табарга һәм саклап калырга булыштылар.

Дусларның, туганнарның юбилейларына һәм туйларына багышлап күп кенә шигырь-поэмалар иҗат иттем. Бу мөмкинлегем миңа да, башкаларга да зур шатлык китерә, рухыма көч өсти, иҗади эшләргә дәртләндереп тора.  Чынбарлыкта  мин милләт аермыйм, шулай да  татар булуым белән  горурланып яшим. Берничә телне белүдә миңа ярдәм итә.

Безнең  гаиләдә хәләл җефетем Әлфия, ике улыбыз Ленар һәм Алмаз да, оныкларыбыз да татар телен, гадәтләрен ихтирам итәләр, милли музыканы һәм әдәбиятне өйрәнәләр. Балаларыбыз тәртипле, акыллы, сабыр халыклы, өлкәннәргә

ихтирамлы, әби-бабайларының истәлеген саклаучылар булып үсәләр. Өлкән улыбыз югары белемле күз табибы-хирург, безнең шәхси клиникабызда эшләп зур хөрмәткә лаек булды. Гиләсендә ике малай тәрбиялиләр. Кече улыбыз Алмаз югары белемле юрист-судья вазифасын зур осталык һәм гаделлек белән башкара, абруйлы хезмәткәр.

Мулланур Вахитов исемендәге мәктәп коллективының көзгесе, тырыш хезмәтнең җимеше булып, безнең 1965 елда 11 “А” һәм 11 “Б” классларының тәмамлаган укучыларыбыз! Аларның 60% үз көчләре белән югары укку йортларына керделәр һәм үз профессияләрнең чын остасы булып, гаделлек белән хезмәт итеп, зур абруйлар яуладылар. Берничә мисал: минем дусларымнан Юмагулов Нәҗип КАИны алтын медальгә тәмамлап, кафедрада эшләп, техник фәннәр кандидаты дәрәҗәсен алды. Академик булырлык сәләте дә бар иде, ләкин иртә мәхрүм булды, урыны оҗмахта булсын. Икенче дустым Әхмәтшин Рәшит Казан педагогия институтын тәмамлап, КГБ (ФСБ) системасында эшләп, полковник дәрәҗәсенә җитте. Әфганстанда хезмәт итеп, күп Дәүләт бүләкләренә лаек булды.

Мин үзем Казан медицина институтын тәмамлап, югары категорияле күз табибы булып эшлим, стажым 45 ел, балалар һәм өлкәннәрнең күрү сәләтен арттырам. Берничә ел Казанда сәламәтлек саклау министырлыгында Татарстанның баш күз табибы вазыйфасын үтәдем. Бүгенге көндә үзебез ачкан күз клиникасында гаиләм белән хезмәт итәм.

Без барыбыз да хезмәттә, гаилә коруда, тәрбияле балалар һәм оныклар үстерүдә ирешкән уңышларыбыз өчен 2 нче номерлы Чаллы татар мәктәбе коллективына рәхмәтлебез һәм бурычлыбыз. Барыгызга да саулык, бәхетле озын гомер, шат күңелле булуыгызны телибез. Вафат булганнарның туфраклары җиңел, җаннары җәннәттә булсын, истәлекләре онытылмасын, яңа буыннар белән чылбырлары өзелмәсен.

Хәзерге көндә Татар гимназиясенең шәһәр Советы депутаты Фирдүсә Әюпова җитәкли. Үз эшенең остасы, Гаҗәеп бай тәҗрибәсе белән барыбызны да сокландырып, 25 ел буена шушы яраткан эшендә.

Эшнең уңышы җитәкчеләрдән башлана. Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Энҗе Харисова укучы балаларга төпле белем бирү, сәләтләрен үстерү, әхлакый гүзәл сыйфатлар тәрбияләү юнәлешендә эшли.

Гимназиянең киләчәге ышанычлы кулларда, чәчкән алтын орлыкларыгыз уңдырышлы җирдә үссеннәр!

***Ихтирам белән: Фаяз Газизов***